Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының унсигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 декабрь, 2021 ел № 132

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2021 елның 3 декабрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләргә:

- индивидуаль торак төзелеше өчен: минималь мәйдан - 1000 кв.м., максималь мәйдан - 2500 кв.м.;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен: минималь мәйдан - 1000 кв.м., максималь мәйдан - 3000 кв.м.;
- блокланган торак төзелеше өчен: минималь мәйдан - 1000 кв. м., максималь мәйдан - 2000 кв.м.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына әлеге карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов